ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 98 статьяның 13 өлешендәге 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«6) пестицидларны һәм агрохимикатларны саклау һәм куллану;»;

2) 122 статьяның 1 өлешендә «хайваннар дөньясын дәүләт исәбенә алу һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 123 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

4) 125 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«125 статья. **Хайваннар дөньясыннан файдалануда чикләүләр**

1. Хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлеген саклау максатларында хайваннар дөньясыннан файдалануда түбәндәге чикләүләр билгеләнергә мөмкин:
1) билгеле территорияләрдә (акваторияләрдә) хайваннар дөньясыннан файдалануның аерым төрләрен гамәлгә ашыруны тыю;

2) билгеле территорияләрдә (акваторияләрдә) хайваннар дөньясының кайбер объектларыннан файдалануны чикләү;

3) хайваннар дөньясы объектларыннан файдалану чорларын (срокларын) билгеләү;

4) хайваннар дөньясы объектларын аулап алу өчен куллануга рөхсәт ителә торган корал төрләрен һәм ысулларын билгеләү;

5) хайваннар дөньясыннан файдаланудагы федераль законнар нигезендә билгеләнгән башка чикләүләр.

2. Хайваннар дөньясыннан файдалануда чикләүләр, аучылыкны һәм балыкчылыкны чикләүләрдән тыш, вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы яисә федераль башкарма хакимиятнең хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлеген саклау, торгызу һәм алардан файдалану өлкәсендә федераль дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы органы белән килештереп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.»;

5) $135^2$ статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Аучылык ресурсларын һәм аларның яшәү тирәлеген дәүләт тарафыннан мониторинглау түбәндәгеләрне даими рәвештә күзәтүләр системасыннан гыйбарәт:

1) аучылык ресурсларының санын һәм аларны бетерү күләмнәрен;

2) аучылык ресурсларының таралышын, аларның торышын һәм төрләр буенча санының үзгәрү динамикасын;

3) аучылык ресурслары яшәү тирәлегенең торышын.»;

б) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Аучылык ресурсларын һәм аларның яшәү тирәлеген дәүләт тарафыннан мониторинглау күрсәткечләре табигый һәм (яисә) антропоген факторларның йогынтысында аучылык ресурслары һәм аларның яшәү тирәлеге торышындагы үзгәрешләрне ачыклау, аларны бәяләү һәм фаразлау, дәүләт аучылык хуҗалыгы реестрын булдыру максатларында, шулай ук аучылык ресурсларыннан нәтиҗәле файдалануны оештыру, аучылык ресурсларын һәм аларның яшәү тирәлеген саклау максатларында кулланыла.»;

6) $135^3$ статьяда:

а) 2 өлештә «алып бару һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 3 өлештә «аны алып бару технологиясенең бердәмлеге, андагы документлаштырылган мәгълүматның һәркем өчен мөмкин булуын һәм аны актуальләштерүнең өзексезлеген тәэмин итү, мондый мәгълүматны башка дәүләт мәгълүмат ресурсларындагы документлаштырылган мәгълүмат белән чагыштырып булу принциплары нигезендә кәгазь һәм электрон чыганакларда» сүзләрен «андагы документлаштырылган мәгълүматның һәркем өчен мөмкин булуын һәм аны актуальләштерүнең өзексезлеген тәэмин итү, мондый мәгълүматны башка дәүләт мәгълүмат ресурсларындагы документлаштырылган

мәгълүмат белән чагыштырып булу принциплары нигезендә» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге статьяда аларның үз көчләренә керүенең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләрдән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 – 6 пунктлары 2021 елның 1 августыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 16 июль
№ 49-ТРЗ